Республика Татарстан
Совет Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

06.08.2019 Менделеевск ш. №209

Менделеевск муниципаль районының Советы 2015 елның 27 октябрендәге 18 номерлы «Менделеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнары структурасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы «Опека һәм попечительлек турында» Федераль законы кысаларында Менделеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Менделеевск муниципаль районы советының 2015 елның 27 октябрендәге 18 номерлы «Менделеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнары структурасын раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегендә опека һәм попечительлек секторын булдырырга.

1.2. Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге структурасын кушымта нигезендә расларга..

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Советының законлылыкны, хокук тәртибен, кеше хокукларын һәм депутат этикасын саклау буенча даими комитетына йөкләргә.

Менделеевск муниципаль районы
Советы рәисе Чершинцев В.С.

КУШЫМТА

Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты Аппараты
СОВЕТЫ

| № | Вазыйфаның исеме | Берәмлекләр саны |
| --- | --- | --- |
| ***опека һәм попечительлек бүлеге*** | | |
| 1 | Бүлек җитәкчесе | 1 |
| 2 | Бүлек башлыгы урынбасары | 1 |
| 3 | Бүлекнең баш белгече | 1 |
| | БАРЛЫГЫ | 3 |